УПРАВЛЕНИЕ
ПО ОХРАНЕ И
ИСПОЛЬЗОВАНИЮ
ОБЪЕКТОВ
ЖИВОТНОГО МИРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
ҺӘМ АЛАРДАН
ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

---

**Приказ** **Боерык**

24.07.2017 г. Казань № 101-од

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче гражданнар һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) “Интернет” мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

2004 елның 27 июленнән 79-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” гы Федераль канунның 20.2 маддәсе, 2003 елның 16 гыйнварыннан 3-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында” гы Татарстан Республикасы Кануныңың 17.2 маддәсе белән тәңгәл килеп **боерам:**

1. Теркәлгән Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче гражданнар һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) “Интернет” мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен расларга.
2. Бу боерыкның үтәлүен тикшерүне үз артымнан калдырам.

Идарә башлыгының вазифаларын үтәүче Ю.Б.Матвеев

Татарстан Республикасының
хайваннар дөньясы
объектларын саклау һәм
алардан файдалану Идарәсе
башлыгы вазифаларын
үтәүчесенең 24.07.2017
елдан 101-од номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче граждannar һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) "Интернет" мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми кагыйдәләр

1. Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче граждannar һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) "Интернет" мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе ( алга таба – Тәртип) урнаштыра:

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче граждannar ( алга таба – гражданин) һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре, Идарә) белән, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) "Интернет" мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турындагы мәгълүматларны тапшыру кагыйдәләре.( алга таба – Сайтлар турында мәгълүмат, "Интернет" челтәре);

сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе;

сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе.

2. 2006 елның 27 июленнән 149-ФЗ номерлы “Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында” гы Федераль канунның 7 маддә 1нче бүлеге белән тәңгәл килеп, һәркемгә ачык мәгълүмат астында, рөхсәт чикләнмәгән иҗтимагый һәм башка мәгълүматлар күз алдына китерелә. Шул ук вакытта мәгълүматка чикләүләр куелмау, гражданның яки гражданлык хезмәткәренең рөхсәтеннән башка, чикләнмәгән даирә затлар белән, урнаштырылган мәгълүматны чикләүсез алуны һәм уз карары буенча куллануны күз алдында тота.

3. Гражданның яки гражданлык хезмәткәренең шәхесен тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүмат булып, киләсе мәгълүмат яки аларның барлыгы килергә мөмкин:фамилия һәм исем, фотография, хезмәт урыны.

## II.Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшыралар:

гражданин – Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенә кергәндә ( алга таба - гражданлык хезмәте) гражданлык хезмәтенә керер алдыннан килгән өч календарь ел өчен;

гражданлык хезмәткәре – ел саен, алдан килгән календарь ел өчен, хисап елыннан соң килгән елның 1 апреленнән дә соңа калмыйча.

5. Сайтлар турында мәгълүматлар, гражданнар һәм гражданлык хезмәткәре белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча биреләләр (алга таба – Форма).

6. Һәркемгә ачык мәгълүмат, әгәр дә гражданлык хезмәткәре үз вазифасын үтәү чикләрендә урнаштырса, Формада чагылдырылмый.

7. Тутырылган Форма, гражданин һәм гражданлык хезмәткәре белән, Идарә башлыгы боерыгы нигезендә, сайтлар турында мәгълүматларны эшкәртү өчен җаваплы булып билгеләнгән, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлеге хезмәткәренә (алга таба – җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат, Форманы алган көнне, Форма тутыруның тулылыгын, “Интернет” челтәрен кулланып, анда күрсәтелгән мәгълүматның дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, бу Тәртипнең Кушымтасындагы форма буенча мәгълүматларны журналга терки.

9. Баганалары тулысынча тутырылмаган Форма кабул ителми.

10. Гражданин белән тапшырылган Формада, дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланган очракта, эш башкару өчен җаваплы хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлеге хезмәткәре, аны гражданлык хезмәте вазифасына алуны кире кагу турында тоткарсыз хәбәр итә.

11. Сайтлар турында мәгълүматлар, җаваплы зат белән, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәткәрләр һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр кадрлар катнашмасының бердәм мәгълүмати системасы”ндагы гражданлык хезмәткәрләренең шәхси карточкаларына кертелә.

12. Гражданнар яки гражданлык хезмәткәре белән тапшырылган Формалар,

хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлегендә, биш ел дәверендә саклаактар. Анан соң, Идарәдә шәхси мәгълүматларны эшкәртү Кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә, юк ителәләр

## III.Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе.

13. Гражданлык хезмәткәрләре белән тапшырылган, Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, Идарә башлыгы( Идарә башлыгы вазифаларын үтәүче зат) ( алга таба – Идарә башлыгы) боерыгы буенча башкарыла

14. Тикшерү өчен нигез булып, түбәндәге әгъзалардан, язмача бирелгән байтак мәгълүмат килә:

хокук саклаучы әгъзалар, башка дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм аларның вазифаи затлары;

даими эшли торган сәяси партияләрнең һәм канун белән тәңгәл килеп теркәлгән, сәяси партия булып килмәгән, башка бөтенроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең җитәкләүче әгъзалары;

Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы;

бөтенроссия һәм республика массакүләм мәгълүмати чаралары.

15. Җаваплы зат, гражданлык хезмәткәренә, аңа карата тикшерү башлануы турында, тикшерүне уздыру турында боерык чыкканнан соң ике көн эчендә, язмача хәбәр итә.

16. Гражданлык хезмәткәрләре белән тапшырылган, Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, җаваплы зат белән, “Интернет” челтәрендә урнаштырылган һәркемгә ачык мәгълүматны эзләү һәм аның электрон копияләрен ( скриншотлар) ясау юлы белән алып барыла

17. Гражданлык хезмәткәре, тикшерү барышында һәм аның нәтиҗәсе буенча, язмача рәвештә аңлатмалар бирергә һәм өстәмә мәгълүматлар тапшырырга хокуклы.

18. Бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән, аңлатмалар, тикшерү материалларына теркәләләр.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүматлар, тикшерүне уздыру турында боерык чыкканнан соң 10 эш көне эчендә, Идарә башлыгына тапшырылалар.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көн эчендә Идарә башлыгы карар кабул итә:

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллануга нигезләр булмау турында;

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

хокук бозу, җинаять, экстремизм эшчәнлеге сыйфатлары ачыкланса, тикшерү материалларын, аларның компетенцияләренә тәңгәл килүче, дәүләт әгъзаларына юнәлтү турында.

21. Җаваплы зат, аңа карата тикшерү уздырылган гражданлык хезмәткәренә, Идарә башлыгы белән кабул ителгән карар турында, язмача рәвештә ике эш көне эчендә хәбәр итә.

Идарә башлыгының язмача рөхсәте белән, шул ук вакытта аңа карата тикшерү уздырылган гражданлык хезмәткәренә хәбәр итеп, сайтлар турында мәгълүматлар, шәхси мәгълүматлар һәм дәүләт сере турындагы Россия Федерациясе кануннарын саклап, алар белән бирелгән мәгълүмат тикшерүне уздыру өчен нигез булып килгән, хокук саклаучы әгъзаларга, даими эшли торган сәяси партияләрнең һәм канун белән тәңгәл килеп теркәлгән, сәяси партия булып килмәгән, башка бөтенроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең җитәкләүче әгъзаларына,Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасына, бөтенроссия һәм республика массакүләм мәгълүмати чараларына тапшырылырга мөмкин.

22. Тикшерү материаллары хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлегендә, өч ел дәверендә сакланалар. Соңыннан архивка тапшырылалар.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшырмау өчен җаваплылык.

23. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшырмаган очракта, гражданин гражданлык хезмәтенә алына алмый, ә гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтендә кала алмый.

24. Гражданлык хезмәткәре белән Сайтлар турында мәгълүматларны тапшырмау канун бозу булып санала һәм үз артыннан гражданлык хезмәтеннән азат ителүне тарта.

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче гражданнар һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) "Интернет" мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибенә Кушымта

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын алмаштырырга теләүче гражданнар һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре, һәркемгә ачык мәгълүматны, ә шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны урнаштырган сайт адреслары һәм (яки) "Интернет" мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә сайт битләре турында бирелгән мәгълүматларны теркәү журналы

| № | Форманы бирү\алу вакыты | Форманы тапшырган затның исеме, фамилиясе, атасының исеме | Форманы тапшырган затның вазифасы (гражданин дәгъвалаган вазыйфа) | Форманы тапшырган затның имзасы(яки почта аша җибәрелсә керү №) | Форманы кабул иткән затның исеме, фамилиясе, атасының исеме | Форманы кабул иткән затның имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерыкның реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |